ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8 статьяларына һәм Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 150 һәм 152 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктындагы унынчы абзацында «18 яшькә кадәрге» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 8 статьяда:
а) исемдә «18 яшькә кадәрге» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 8 пунктта:
беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8. Әлеге статьяның 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән социаль ярдәм чараларына өстәмә рәвештә гаилә составында, уллыкка алынган балаларны да кертеп, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга, өлкән балага 18 яшь

тулганчы яисә 23 яшь тулганчы, ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку рәвешендә белем алган очракта, социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:»;

бишенче абзацта «һәм һөнәри белем бирү оешмаларында» сүзләрен төшереп калдырырга, «алар укып бетергәнче, әмма унсигез яшькә җиткәннән соң түгел» сүзләрен «алар укып бетергәнче, әмма аларга 23 яшь тулганчы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 150 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«150 статья. **Күпбалалы гаилә**

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә булып өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаилә санала, аның статусы чикләнмәгән вакытка билгеләнә.»;

2) 152 статьяда «Татарстан Республикасы законнары нигезендә» сүзләрен «Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2024 елның 23 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. Гаилә составында, уллыкка алынган балаларны да кертеп, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга, әлеге Закон үз көченә кергән көнгә һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучыларга транспортта йөрүгә айлык субсидия билгеләнгән булса, транспортта йөрүгә күрсәтелгән айлык субсидия балалар укып бетергәнче, әмма аларга 18 яшь тулганчы түләнә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 15-ТРЗ